ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСЕНБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСӘНБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2021 Исәнбай авылы № 6

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим билгеләү турында» Әгерҗе муниципаль районының 2021 елның 23 апрелендәге 4 номерлы Исәнбай авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим билгеләү турында» Әгерҗе муниципаль районының 2021 елның 23 апрелендәге 4 номерлы Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1нче кушымтасында 4, 5, 6 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе